РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2020 елның 16 мае

2нче номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
«Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә
"Түбән Наратбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге
чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар
уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» 2020 елның 15 маендагы 3-53 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карары нигезендә, Түбән Наратбаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләре турындагы проектны гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә "Түбән Наратбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыруны Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 16 июненә 11.00 сәгаткә билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларда фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 15 июненә кадәр Түбән Наратбаш авылы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге башкарма комитеты, Совет урамы, 2А йорт адресы буенча кабул ителә, телефон 3-36-45.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча һәм Түбән Наратбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш
авыл җирлеге башлыгы

И.И. Галиуллин